БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» 11 2022 ел № 323

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем алучыларны бушлай кайнар ризык белән тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны кайнар ризык белән тукландыруның уртача бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2013 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясына, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына туры китереп, «"Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында" 2022 елның 14 сентябрендәге 991 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 3 октябрендәге 1065 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем алучыларны бушлай кайнар ризык белән тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны 2023 елга бер белем алучыга бер көнгә 64,19 сум, 2024 елга - 66,76 сум, 2025 елга - 69,43 сум күләмендә;

башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны кайнар ризык белән тукландыруның уртача бәясен 2023 елга бер белем алучыга 64,19 сум, 2024 елга - 66,76 сум, 2025 елга - 69,43 сум күләмендә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ начальнигына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.С.Галимуллин